**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75 а йорты
e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru

**СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423737, село Атясево, ул. Центральная, д. 75 а
e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«20» апрель 2020 ел** **№ 8**

**«Җир салымы турында» 20.11. 2014 ел 19 номерлы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге (икенче өлеш), Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Әтәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Җир салымы турында» 20.11. 2014 елның 19 номерлы Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- 1,5% мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, дәүләт автоном һәм бюджет учреждениеләре сәнгате объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата, милек хокукындагы яисә муниципаль автоном һәм бюджет учреждениеләреннән даими сроксыз файдалану хокукындагы шундый объектлардан тыш;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы, Әтәс авылы, Үзәк урамы, 75а йорты, Иске Бикчәнтәй авылы, Г.Тукай урамы, 3 нче йорт адресы буенча урнашкан, Татарстан Республикасы, Актаныш муниципаль районы Әтәс авыл җирлегенең рәсми сайтында халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Насыйрова